ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЫПЧЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чыпчык авылы, Совет ур.,1

СОВЕТ ЧЕПЧУГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Чепчуги , ул. Советская, д. 1

тел./факс 8(84365)72-5-01 e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

КАРАР
18 июль 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 122

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге тарафыннан шәһәр төзелеше өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында**

Биектау муниципаль районы Советының “Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләрне раслау турында”, 2019 елның 30 маендагы 300 номерлы карарын караганнан соң, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “Чыпчык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. 3 һәм 4 бүлекләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру өлешендә вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә.

Кабул ителә торган вәкаләтләрнең тормышка ашыру предметы булып торалар:
- җирлекнең генераль планын раслау;
- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;
- җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативларын раслау.

2. Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру буенча килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Чыпчык авыл җирлеге Башлыгына имза куюга тапшырырга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

Совет рәисе,
Чыпчык авыл җирлеге башлыгы — И.Р.Җиһаншин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Чыпчык
авыл җирлеге
Советы
Совет Чепчуговского
сельского
поселения
ИНН 1616004928
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ВЫСОКОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН